| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 7 КАРАР

12ноябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылында 2026 елга үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә:

1.Сөлек авылы клубы бинасында Сөлек авылы, Мәктәп урамы, 56 йорт адресы буенча 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 18 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертүгә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Сөлек торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу);)

2) Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү(төзелеш материаллары сатып алу);

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, Мәктәп урамында зур агачлар кисү)? »

«ӘЙЕ» ЮК".

3.Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгының «2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турындагы "05.11.2025 ел, № 4 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Сөлек авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина